ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 ноябрь 2020 ел № 5738

Башкарма комитетның 2013 елның 19 августындагы 4918 номерлы карары белән расланган социаль наем шартнамәсе буенча гражданга муниципаль милектәге торак урынны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 19 августындагы 4918 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 12 апрелендәге 1821 номерлы, 2016 елның 27 июнендәге 3273 номерлы, 2017 елның 29 сентябрендәге 5873 номерлы, 2018 елның 28 апрелендәге 2397 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6596 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган социаль наем шартнамәсе буенча гражданга муниципаль милектәге торак урынны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.5 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) гариза;

2) гариза бирүче гражданның һәм аның гаилә әгъзаларының паспорт яки шәхесне ачыклаучы башка документларының күчермәләре;

3) гариза бирүче гражданның гаилә составы турында документларының күчермәләре (туу турында таныклык, язылышу турында таныклык, уллыкка (кызлыкка) алу турында карар, гаилә әгъзасы итеп тану турында суд карары һ.б.);

4) гариза бирүче гражданны яисә аның гаилә әгъзасын торак законнары нигезендә чираттан тыш торак урын алу хокукына ия гражданнар категориясенә кертү өчен нигез булып торучы документлар:

- медицина оешмасыннан медицина белешмәсе – гражданның гаилә составында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан расланган исемлек буенча аның белән бер фатирда бергә яшәү мөмкин булмаган хроник авыруның авыр төре белән интегүче авыру булганда;

- опека һәм попечительлек органнарыннан опекун билгеләү турында белешмә – хокукка сәләтсез граждан исеменнән эш итүче опекун итеп исәпкә алу турында гариза имзаланган очракта;

5) 1999 елның 31 декабренә кадәр дәүләт теркәвен гамәлгә ашыра торган дәүләт теркәве органыннан гаилә әгъзаларының даими яшәү урыны буенча милек хокукында торак урыннары булу яки булмау турында гариза бирүче гаиләсенең һәр әгъзасы тарафыннан бирелә торган мәгълүматлар;

6) гариза бирүче граждан һәм аның гаилә әгъзалары биләгән торак урыннан файдалану хокукын раслый торган документлар күчермәләре (1999 елның 31 декабренә кадәр)»

2) 2.6 пунктның икенче баганасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) аерым затның ул ия булган (булучы) күчемсез милек объектларына хокуклары турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

2) күчемсез милек объектына хокуклар күчү турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

3) күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;

4) торак урында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар санын раслый торган мәгълүматлар;

5) торак урынны яшәү өчен яраксыз дип тану турында карар (граждан яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урында яшәгән очракта)»;

3) 3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма рәвештә гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон гариза Башкарма комитетка электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүне алып баручы белгече гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч кәгазе буенча эш иткәндә);

әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә каралган документларның булуын тикшерүне;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

гариза бирүчегә документларны кабул итү датасын, бирелгән керү номерын күрсәтеп гаризаның күчермәсен бирү.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документлар кабул итүне алып баручы белгече, гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Башкарма комитет Җитәкчесенә карап тикшерү өчен җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны карап тикшерә һәм аны идарәгә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: идарәгә җибәрелгән гариза һәм документлар.»;

4) 3.4.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә белгече электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кирәкле мәгълүматларны бирү турында запрослар җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүматлар тапшыру турында запрослар.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Ф.Ш. Салахов